02-07

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ “КҮБӘЛӘК” БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”
422065, Татарстан Республикасы,
Олы Кибәче авылы , Ф.Энгельс урамы, 75 йорт
Тел. 42-6-39

Emailkibichisaba.ds@yandex.ru

“БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКИЙ ДЕТСКИЙ САД “КУБЭЛЭК” САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН”
422065, Республика Татарстан,
с. Большие Кибячи, ул. Ф.Энгельса, 75

Принято на заседании педагогического совета № 1
От 28.08 2025г.

Утверждаю
Заведующий МБДОУ-«Большекибячинский детский сад «Күбәләк»
Шакирова Р.Ш.
Приказ№ 44 от 28.08. 2025г.

# 2025-2026 нчы уку елына тәрбия эшенең календарь тематик планы

| № | Атна темасы | Вакыт | Максатлары | Йомгаклау чарасы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Безнең балалар бакчасы | 1-6 сентябрь | Балалар бакчасы шартларына ияләштерү. Баланың социаль мохите буларак, балалар бакчасы (бакча бинасы һәм төркем бүлмәсендәге җиһазлар: шкаф, караваты, уенчыклар һ.б.) белән таныштыру. Балаларны бер-берсе һәм тәрбияче белән таныштыру. Балалар бакчасына йөрү, яшьтәшләре белән аралашуның балаларда уңай эмоцияләр тудыруына ирешү. | "Серле йомгаклар" |
| 2. | Безнең төркем | 8-13 сентябрь | Балаларны тәрбияче апалары, бер-берсе, бакча бүлмәләре белән таныштыру. Педагог көзге табигать күренешләренә игътибар юнәлтә: кояш яктырта, агачларда яфракларның саргаюы, яңгыр сибәли һ.б. Балаларның бер-берсенә комачауламыйча, уен аша контактка керүләренә ирешү. | "Куян сәяхәткә чакыра" |
| 3. | Көз күчтәнәчләре | 15-20 сентябрь | Табигатьтә көз фасылы һәм андагы үзгәрешләрне күзаллау; көзнең матурлыгын күрә һәм соклана белүләренә ирешү. Балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, кызыксынучанлык тәрбияләү. Җәй һәм көз фасылларының үзгәрешләрен аера һәм күрә белүләренә ирешү. | "Көзге мизгел" |
| 4. | Йорт хайваннары | 22-27 сентябрь | Балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; бозау, бәрән, кәҗә бәтие сүзләре хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру; тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру; игътибарны, хәтерне үстерү; башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | "Ак песи" |
| 5. | "Минем илем, минем өем" | 29 сентябрь - 4 октябрь | Балаларда үзең яшәгән урын, авыл турында башлангыч белем бирү, үзенең туган авылына, үзе яши торган авылның табигатенә, туган йортыңа мәхәббәт тәрбияләү. Үзе яши торган авылның, үзе йори торган бакчаның, үзе йори торган төркемнең, | "Минем гаиләм" |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | әти-әнисенең, үзенең исемен дөрес итеп әйтеп бирергә өйрәтү, балаларның аңга алуларын, игътибарларын, фикерләүләрен үстерү, тәрбияче сорауларына тулы җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү. | |
| 6. | “Минем гаиләм” | 6-11 октябрь | Балаларда гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү. Балаларның гаилә әгъзалары белән танышу. Әби-бабайларның кадерле кешеләр булуын төшендерү, гаилә дуслыгы турында аңлату, гаиләдә бер-береңә игътибарлылык, ярдәмләшү һәм дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү. | “Әбием мине сагынган” |
| 7. | “Сабам-минем туган җирем” | 13-18 октябрь | Балаларда туган авылыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү. Туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү. Туып үскән җиргә мәхәббәт тәрбияләү. | “Туган авылым” |
| 8. | “Китап – киңәшчең синең”<br>Мониторинг | 20-25 октябрь | Балаларда китапларга карата кызыксыну уяту, китапларның рәсемнәрен, битләрен ертмыйча сак кына ачып карарга, укылган әкиятләрнең исемнәрен искә төшерү, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын үстерү. Китапларны билгеле урынга гына куярга күнектерү. | “Китаплар күргәзмәсе” |
| 9. | “Әдәплелек дәресләре” | 27-1 ноябрь | Балаларның танып-белү активлыгын үстерү; табын әдәбе белән таныштыру; кунакчыл булырга өйрәтү; үзеңне әдәпле тоту күнекмәләре булдыру; кунакчыллык, чисталык кебек күркәм сыйфатлар, савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү; савыт-саба атамаларын ачыклау, савыт-сабаларның өлешләрен атый белергә өйрәтү. | “Мин әбидә кунакта” |
| 10. | “Минем гаиләм, йорт җиһазлары” | 3-8 ноябрь | Балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; бәйләнешле сөйләм үстерү; сөйләмдә грамматик формаларны куллану күнекмәләре бирү; гаиләдә бер-береңә игътибарлылык, ярдәмләшү һәм дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген үстерү; йорт җиһазларына карата сак караш, | “Мин әниемә булышам” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. | |
| 11. | “Юлларда иминлек” | 10-15 ноябрь | Балаларны урам, андагы объектлар, күренешләр белән таныштыру, аларга карата кызыксыну тудыру. Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәр-бияләү. Юлларда күзәтүчәнлекне үстерү. Юл билгеләрен аера белү. Юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәтү. | “Белмәмеш бездә кунакта” |
| 12. | ”Йорт кошлары “ | 17-22 ноябрь | Балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү; сөйләмне *томшык, тавык, чебиләр, табак* сүзләре хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү; йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. | "Кошлар-безнең дуслар " |
| 13. | “Әнием минем” | 24-29 ноябрь | Әниләргә карата миһербанлылык тәрбияләү, ярдәм итү теләге булдыру, әйләнә-тирә предметлар, савыт-сабаның әһәмиятен өйрәтү, балаларга әниләр бәйрәме турында төшенчә бирү. | “Әниләр бәйрәме!” |
| 14. | Кыргый җәнлекләр | 1 декабрь – 6 декабрь | Балаларның кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү; авазлар артикуляциясен ныгыту; җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту, җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү; бала-ларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйль-леген үстерү; җәнлекләр белән кызыксындыру. Балаларда кыргый хай-ваннарга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү. Мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү, балаларны кыргый хайваннар, аларның тышкы билгеләре, яшәү рәвешләре белән таныштыруны дәвам итү. | “Кышкы урманга сәяхәт” |
| 15. | Кыш килде | 8декабрь-13 декабрь | Балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; балаларның игътибарын, дио-логлы сөйләмен, сөйләм сулышын; рәсем ясауга кызыксынулары, пространствода ориентлашуларын үстерү; башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | “Кар ява” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16. | Кышлаучы кошлар тормышы | 15-20 декабрь | Балаларның кошлар турындагы күзаллауларын киңәйтү; кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча та-ныырга өйрәтүне дәвам итү; аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү; сүз-лек запасын баету, игътибарларын үстерү; күзәтүчәнлек, кошларга карата сак караш, алар турында кайгыртучанлык, кышын аларны тук-ландырыу теләге тәрбияләү, табигатьне яратырга, сакларга өйрәтү. | Кошларга җимлекләр кую. |
| 18. | Хуш киләсең яңа ел! | 22-27 декабрь | Балалар белән чыршыны бергәләп карау, Яңа ел бәйрәме ту-рындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету; балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү; матурлыкны күрә һәм соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, танып белү ак-тивлыкларын формалаштыру; балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру. | “Чыршы бәйрәме” |
| 19. | Халык җәүһәрләре Савыт-саба. | 29-10 январь | Савыт-сабаның аерым предметлары, аларның кулланылышы турында белемнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; балаларны әңгәмәгә тарту; балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү; балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә булышу теләге уяту; савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү. | «Әби-бабайларны хөрмәтлик!» |
| 20. | Кыш билгеләре. | 12-17 январь | Балаларның кыш турында белемнәрен ныгыту; балаларның күрсәтмә образлы фикерләвен үстерү; туган табигатькә мәхәббәт һәм эстетик хисләр тәрбияләү. | “Кар ява” |

4

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21. | “Сәламәт булыйк!” | 19-24 январь | Балаларны мөстәкыйль рәвештә үз сәламәтлекләрен кайгыртырга өйрәтү, үз-үзләренә ярдәм күрсәтү күнекмәләрен ныгыту, балаларның сөйләмен үстерү өстендә эш, мәкальләрнең эчтәлекләрен аңларга чакыру, физик күнегүләр һәм үз-үзләренә массаж ясауга кызыксыну тудыру. | “Куян кызы” әкият уку. |
| 22. | Җәнлекләр кышкы урманда. | 26 январь - 31 январь | Балаларның җәнлекләр турында күзаллауларын формалаштыру; табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту; бәйләнешле сөйләм үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. | “Кышкы урманга сәяхәт” |
| 23. | Алсуны киендерәбез | 2-7 февраль | Кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, аерым детальләрен, материалын атап, аны сурәтләргә; исемне сыйфат белән бәйләп, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел, зәңгәр сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүләрен, игътибарларын, күрү хәтерләрен үстерү; киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. | Алсу бәйрәмгә җыена» дидактик уены |
| 24. | Мин - дөньяның бер кешесе. “Минем исемем бар” | 9-14 февраль | Баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү; тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү; балаларның хәтерен, игътибарын үстерү; балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрен ачыклау һәм ныгыту; гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, бо-рын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүз-леген активлаштыру; үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы | Әти-әниләр белән берлектә “Минем яратуга һәм кайгыртуга хокукым бар” темасына рәсем күргәзмәсе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | булу, культура - гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. | |
| 25. | Безнең этиләр | 16-21 февраль | Балаларны этиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрне карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү; эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү, балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү; төрле һөнәр кешеләренә һәм этиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту, этиләре белән горурлану хисе тәрбияләү, балаларның уй-фикерләү сәләтен камилләштерү, балаларга Ватанны саклаучылар турында башлангыч төшенчә бирү. | “Әтиемә” шигырләр кичәсе |
| 26. | Тиздән яз. | 24-28 февраль | Балаларны язгы күренешләр белән таныштыру (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), балаларга язгы күренешләр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) турында башлангыч белемнәр бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру; табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру, язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта - көннәр җылына - кар эри һ.б.) ачыклау барышында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру; балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү; язгы күренешләр белән кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту. | Яз турында рәсемнәр ясау. |
| 27. | Әниләр бәйрәме. | 2-7 март | Әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү; балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү; төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү.әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү; балаларның игътибарын, | “Әни кирәк!”бәйрәм кичәсе. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | кабул итүләрен, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү; балаларда әниләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү | |
| 28. | Су яшәү чыганагы. | 9-14 март | Гигиена күнекмәләре тәрбияләү. текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрәтү; [йу] аваз кушылмасын дөрес итеп әйтергә күнектерү, сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру; кабул итү сәләтен, игътибарны, кызыксынучанлыкны үстерү; гигиена күнекмәләре тәрбияләү. | Тыныч уен «Салават күпере». |
| 29. | Ут янында сак бул! | 16-21 март | Электр турында балаларга гади төшенчә бирү (электр тогы электр чыбыкларында «яши»; утны яндыру өчен, өзгечкә (выключательгә) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток йөри башлый); *электр, ток, чыбык, өзгеч (выключатель)* сүзләре хисабына сүзлекне үстерү һәм активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итү сәләтен үстерү; ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү. | Мәче йорты-мультфильмын карау. |
| 30. | Транспорт төрләре. | 23 март-28 март | Балаларны уенчыкларның өлешләрен, төсен, формасын ае-рырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән ярак-лаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; [у] су-зык авазын әйтүдә күнектерү, сүзлекне активлаштыру; уенчыклар белән таныштыруны дәвам итү; балаларның нинди? кайда? нәрсә ташый? сорауларына төзек гади җөмләләр белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү; шофёр, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. | Күмәк эш: “Гараж” төзү. |
| 31. | Урман –күп катлы йорт. | 30март-4 апрель | Балаларның кыргый хайваннар турындагы күзаллауларын формалаштыру, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турын-дагы белемнәрен ныгыту; бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. | “Урманга сәяхәт”-уен эшчәнлек. |
| 32. | “Күк йөзендә ниләр бар?” | 6-11 апрель | Балаларга Кояш, ай, күк йөзе турында башлангыч белем бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту, беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре | “Зөһрә йолдыз” легендасына гадәти булмаган ысул белән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | тәрбияләү, (галәм, орбита, планета, глобус, космонавт, ракета, Кояш системасы.) сүзләре хисабына сүзлекне үстерү һәм активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итү сәләтен үстерү | рәсем ясау. |
| 33. | Хезмәт- төбе хәзинә | 13-18 апрель | Балаларны олылар хезмәте белән таныштыруны дәвам итү (балта остасы хезмәте), хезмәт кораллары турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү, хезмәт коралларын төркемләү осталыгын, игътибарын, олылар хезмәтенә карата кызыксынуын үстерү; | Тукай безнең күңелләрдә. |
| 34. | Г.Тукай –безнең күңелләрдә. | 20 – 25 апрель | Балаларда Г.Тукай әсәрләренә карата кызыксынучанлык тәрбияләү. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарлылыгын, иҗадилыкларын үстерү; балаларда оештыру һәм алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру, үзләренең эш-гамәлләрен, уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклаштырырга өйрәтү | Ә.Ерикәй. «Эти йорт төзи». |
| 3 | Беренче яшеллек | 27апрель-2 май. | Балаларны тал агачы, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сүз байлыгын киңәйтү һәм *песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле* сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру; балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; табигать белән кызыксыну, табигать матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү. | Кәгазь пластикасы “Песиле тал |
| 35. | Җиңү алып килгән яз. | 4 май – 9май | Балаларның Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыру, сугышчыларның батырлыгы турында сөйләү, кайбер хәрби һөнәрләр: диңгезчеләр, танкчылар, очучылар, чик сакчылары белән таныштыруны дәвам итү; балаларның | Күмәк эш “Солют”. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү; хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотик, горурлык хисләре тәрбияләү. | |
| 36. Бүлмә гөлләре. | 11-16 май | Балаларда барлык тереклек ияләренә карата шәфкатьлелек, табигатькә сак караш тәрбияләү. Балаларның туфрак турындагы күзаллауларын киңәйтү, бүлмә гөлләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыруны дәвам итү. | Гөлләрне тәрбияләү. |
| 37. Тиздән – җәй!<br>Мониторинг | 18-23май | Җәй турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә, балалар бакчасы мәйданында сезон үзгәрешләре). Балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, аңга алуларын, уңай хис-кичерешләрен үстерү; табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. | Зурлар төркеме белән берлектә авылның ял паркына сәяхәт. |
| 38. Чәчәкләр тормыш яме. | 25-30 май | Балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү, тузганак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү; *тузганак, чәчәк, сабак* сүзләрен сөйләмдә активлаштыру; балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү; табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. | Чәчәк бакчасына максатчан экскурсия. |